КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 10 июнь г.Казань № 544

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын планлаштыру һәм үткәрү буенча эшне оештыру турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 ел, 5 февраль, 58 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын планлаштыру һәм үткәрү буенча эшне оештыру турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 ел, 5 февраль, 58 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә муниципальара һәм төбәк характерындагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү яисә килеп чыгу куркынычы янаганда эвакуация чараларын үткәрүне тәэмин итү эшен оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә муниципальара һәм төбәк характерындагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү яисә килеп чыгу куркынычы янаганда эвакуация чараларын үткәрүне тәэмин итү эшен оештыру турындагы нигезләмәне расларга.»;

2 пунктта «табигый һәм техноген» сүзләрен «муниципальара һәм төбәк» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «табигый һәм техноген характердагы» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чараларын планлаштыру һәм үткәрү буенча эшне оештыру турында нигезләмәдә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә муниципальара һәм төбәк характерындагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү яисә килеп чыгу куркынычы янаганда эвакуация чараларын үткәрүне тәэмин итү эшен оештыру турындагы нигезләмә»;

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы территориясендә муниципальара һәм төбәк характерындагы гадәттән тыш хәлләр (алга таба - гадәттән тыш хәлләр) барлыкка килү яисә килеп чыгу куркынычы янаганда эвакуация чараларын үткәрүне тәэмин итү эшен оештыру тәртибен билгели.»;

2.2 пунктта:

беренче абзацта «табигый һәм техноген характердагы» сүзләрен төшереп калдырырга;

«а» пунктчасының икенче абзацында «табигый һәм техноген характердагы» сүзләрен төшереп калдырырга;

«а» пунктчасының өченче абзацында «табигый һәм техноген характердагы» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Эвакуация чараларын үткәрү гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы булган территорияләрдәге яисә гадәттән тыш хәлләр зоналарында булган территорияләрдәге кешеләрнең гомерен һәм сәламәтлеген саклап калу максатларында гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин